# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ҮСЕМЛЕКЛӘРГӘ БӘЙЛӘНЕШЛЕ КАЙБЕР МӘКАЛЬ, ӘЙТЕМ, СЫНАМЫШ ҺӘМ ЫШАНУЛАР

## АБАГА

- Абага чәчәге ут булыр, атып җиткәнче юк булыр.
- Абага чәчәк аткач (булыр).
- Җиде төн уртасында абага чәчәген ашасаң, кеше күзенә күренмисең.

## АГАЧ

- Агач арасыннан урман күрмәгән.
- Агач башын җил борыр, адәм башын сүз борыр.
- Агач башыннан (очыннан) корый.
- Агач белән агач тиң түгел.
- Агач беленә җимешеннән, адәм – кыланмышыннан.
- Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк.
- Агач нәселе җир үтә керә, адәм нәселе ил үтә керә.
- Агач үз ихтыяры белән урманын ташламый.
- Агач үз төбенә егылыр.
- Агач утырткан ага булган.
- Агач яфрагы (җимеше) белән матур.
- Агач яфрагын очтан ярса – игенне иртә чәч, төптән ярса – соң чәч.
- Агач яфрагын соң койса, ел авыр килә.
- Агач яфрак коймый кар ятмый.
- Агачлардагы бәс – салкынга, томан – җылыга.
- Агачны баштан бөк.
- Агачның асылын корт ашар.
- Агачның башын киссәң, төбе калыр.
- Агачның биегенә, имәннең ныгына асылын.
- Агачта яфрак ничаклы – бездә хәсрәт шулчаклы.
- Агачына күрә алмасы.
- Иелгән агачны кисмиләр.

- Йомшак агачны корт баса.
- Ялгыз агач янына шайтан оялый – яшен вакытында аңа якын барырга ярамый.

**АКСЫРГАК**

- Аксыргак бар җирдә ат үлмәс.

**АКТАМЫР**

- Актамырны ат яратыр.
- Актамыр атка булган үчен сабаннан алыр.

**АЛАБУТА**

- Алабута аш имеш, алтын-көмеш таш имеш.
- Ачлык елны алабута, туклык елны йолкып ута.
- Ак алабута – ачлык елның бодае.

**АЛМА**

- Алма агачыннан ерак төшми.
- Алма яратсаң – гөлен сакла.
- Алманы карамадан карамыйлар.
- Йомшак алманы корт баса.
- Йөкле вакытта хатын-кыз алма ашаса, баласы матур була.
- Кыш сыкы булса, җәй алма була.
- Сау алма саптан төшми.

**АЛМАГАЧ**

- Алмагачны ашласаң, тәмле алма ашарсың.
- Таза алмагачта да черек алма булгалый.

**АНДЫЗ**

- Андыз бар җирдә ат үлмәс, аксыргак бар җирдә ир үлмәс.

**АРПА**

- Алай диеп болай булмый, арпа чәчеп борай булмый.
- Алтын-көмеш таш икән, арпа-бодай аш икән.
- Арпа чәчкән, бодай урмас.
- Корт ашаган урынга арпа яки карабодай чәч.
- Яз көне балык тотканда алабуга белән юрша күбрәк тотылса – бодай, арпа, арыш, борай уңар.

**АРТЫШ**

- Артыш агачыннан җен курка.
- Артыш исеннән шайтан кача, ди.

**АРЫШ**

- Арыш башаксыз булмас, арпа кылчыксыз булмас.
- Арыш чәчсәң – көлгә чәч, солы чәчсәң – суга чәч.
- Арыш чәчсәң, ипи ашарсың.
- Атың барда арыш чәч.
- Майда яңгырлар күп булса, арыш уңар.
- Наҗагай уйный – арыш пешә.

**АРЫШ АНАСЫ**

- Арыш анасы арыштан алда өлгерә.

**АШЛЫК, ИГЕН, ИКМӘК**

- Алтынчы гыйнварда көн җылы булса, кырда икмәк куе булыр.
- Ашлык туйган саен башын түбән ияр.
- Ашлыкның йозагы – салам.
- Иген камылыннан билгеле.
- Игенне җир уңдырмый, тир уңдыра.
- Игеннең җаен иккән белер.
- Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас.
- Кар калын булса, ашлык уңар.
- Көздән иртә кар яумаса, алгы җәйне иген уңышы начар булыр.
- Кыш көне агач бәсләнсә, иген уңа.
- Май ае салкын булса – игенгә туклык.
- Сабан ашлык чәчкәндә яңгыр булса, бакралы булыр.
- Чәчмәгән ашлык үсмәс.

**ӘРЕКМӘН**

- Адәм фәрештә булмас, әрекмән кәбестә булмас.
- Әрекмәнем, кызу капса – яулыгым, баш авыртса – саулыгым.

**ӘРЕМ**

- Арыш чәчкәндә әрем бик ачы булса, арыш яхшы булыр.
- Әрем төбенә гөл үсмәс.

**БАЙТИРӘК**

- Байтирәкнең чайкалуы җилдән.

**БАКРА**

- Бакра чәчкән бодай урмас.
- Сукыр тавыкка бакра – бодай, чирмеш – Ходай.

## БАЛАН

- Балан бал белән тәмле, бал балансыз да тәмле.
- Балан чәчәк атканда балык сикерә.
- Яшен күп булса, баланны корау алыр.

## БАЛТЫРГАН

- Балтырган бал татыр.
- Елына бер балтырган ашамаган кешенең эче кортлар имеш.

## БАСА (АТА КИНДЕР)

- Ата даны белән кыз китә, баса даны белән сүс китә.

## БӘРӘҢГЕ

- Бәрәңге – ярты икмәк.
- Бәрәңге ашаган тук булыр, тез буыны юк булыр.
- Бәрәңге балына чебен җыелмый.
- Җөйсез йомырка була, сөяксез бәрәңге була.
- Майның тугызында солы тишелә башлый, бәрәңге утыртырга вакыт.
- Симән көн үткәч, биш-алты көннән бәрәңге казырга ярый.

## БОДАЙ

- Бирдем бодай, килдем сорай.
- Бодай иләп арпа төшмәс.
- Бодайдан борайны аера белмәү.
- Бодайны томанлы көнне чәчсәң, яхшы булыр.
- Кар кояш белән кипсә, бодай уңар.
- Кояш чыкканда һава кызыл булса, шул көнне бодай чәч.
- Һәммәсе – богъдай, без – салам, барысы яхшы, без яман.
- Яз көнне кар эрегәндә юллар тар калса, бу елны күбрәк бодай, тары, арпа, борчак чәч.

## БОРАЙ

- Әгәр дә яз көне кар бары кояш җылысы белән генә эресә, җил-яңгыр булмаса – бодай, борай уңар.
- Бытбылдык рәттән күп кычкырса, борай уңар.

## БОРЧАК

- Алтынчы гыйнварда ябалак кар яуса, борчак белән чикләвек уңар.
- Борчак бик уңса, яңадан өч елсыз уңмас.

- Борчак үз кузагын оныта.
- Борчак, күпме генә сикерсә дә, табаны вата алмый.
- Борчакның яхшысы читкә чәчри.
- Карлыгач килгәч борчак чәчәргә кирәк.

## ГӨЛ, ЧӘЧӘК

- Гөл төбенә кычыткан үсми.
- Гөл чәнечкесез булмас.
- Гөл чәчкәсеннән билгеле.
- Киткән кызга гөл бүләк итмиләр.
- Матур чәчәкне кырау тиз ала.
- Мәлсез чәчәк яралмас.
- Чәчәк – кыраудан, кыз алдаудан курка.
- Чәчәкне вакытында җыялар.

## ГӨЛ ҖИЛӘГЕ (ГӨЛҖИМЕШ)

- Гөл җиләге чәчәк аткачтын, күкеләр сакаулана, сандугач та сайрамый.

## ГӨМБӘ

- Аяз елны алма күп, явым елны гөмбә күп.
- Гөмбә яңгырдан туймас.
- Җәй көне гел томан булса, гөмбә күп булыр.

## ДАВЫЛ ЧӘЧӘГЕ

- Давыл чәчәген өзсәң, давыл чыгар.

## ҖИЛӘК

- Җиләк җиләккә карап пешә.
- Җиләкне вакытында җыялар.
- Куш җиләк ашасаң, игез бала табарсың.
- Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.

## ҖИМЕШ

- Агач җимеше белән матур.
- Агачта җимеш арткан саен, ботагы күтәрелми.
- Ашамас җирдә җимеш күп.
- Бер агач ике төрле җимеш бирмәс.
- Җиренә күрә җимеше.
- Кыш көне бәс күп булса, агач җимешләре уңар.
- Майның яңгырлы булуы иген-печәнгә файда, җимешкә зыян.
- Томан күп төшсә, җимеш уңар.

### ҖИТЕН

- Җитен талкымыйча йомшармас.
- Кырмыска түмгәгенә таяк тыккач, кырмыскалар таяк башына кадәр менсәләр – җитен озын булыр.
- Табада җитен орлыгы кыздырсаң, әйбер урлаган кешенең бите чабырып чыга.

### ҖИР МАЕ (гөмбә)

- Җир маеның лайласы җиде төрле сызлауга шифа.

### ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК

- Яз көнендә урманнарда зәңгәр чәчәк күп булса, ашлыкны кырау алмас, карабодай бик уңар.

### ЗИРЕК

- Зирек агачы башлап яфрак ярса, җәй яңгырлы һәм җылы була, ә каен агачы башлап ярса, җәй коры була.
- Зиректән дуга бөгелмәс.

### ИМӘН

- Имән агач(ы) – каты агач, каен агач(ы) – чыра агач.
- Имән җиде ел суда ятса, таш булыр.
- Имән каты җиргә төпләнер.
- Имән күмере исле булыр.
- Имәндә алма үсмәс.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш җылы килә.

### ИЯНКЕ

- Нарат төз карап үсәр, иянке иялеп үсәр.

### КАБАК

- Кабак баштан ярылыр.
- Кабак бик зур да, поты бер тиен.
- Кабак кысыр чәчәкле булса, сулагай киндерә үреп, кабак бакчасына ташлыйлар.

### КАЕН

- Каенагач тал булмас, каен суы бал булмас.
- Каен агачында бөресе күп булса, тары бик уңар.
- Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була.
- Каен суы татлы булса, ашлык уңар.
- Каен төбенә тал чыкмас.

- Каен тузына масаер, имән үзенә масаер.
- Каенны өй янына утыртсаң, кайгы була, имеш.
- Каенның тузын макта, имәннең үзен макта.
- Ялгыз каенга кош кунмас.

**КАЕН ҖИЛӘГЕ**

- Кура җиләге дә, каен җиләге дә күп булса, киләсе елга арыш уңар.

**КАРА ӘРЕМ**

- Августта кара әрем тамырының тармаклары юан булса, киләсе ел арыш булыр.

**КАРАБОДАЙ**

- Беренче мартта буран булса, карабодай уңар.
- Егерме өченче апрельдә иртә белән чык күп төшсә, карабодай уңар.
- Сыерчык бала чыгарганда карабодай чәч.
- Яз көне урамнарда кар элегрәк китсә, карабодай яхшы булыр.

**КАРАГАЙ**

- Карагайның көле күп, имәннең күмере күп.

**КАРАМА**

- Карама агачында бөресе күп булса, арпа уңар.
- Карама агачында чәчәк булса, карабодай уңар.
- Карышып үскән караманы турайта алмассың.

**КАРБЫЗ**

- Буш карбызда орлык күп.
- Ике карбыз бер култыкка сыймас.
- Ярык карбызда тәм булмас.

**КАМЫШ, ҖИКӘН**

- Бетеше яман камышны су эчендә ут алыр.
- Җиренә күрә җикәне.
- Камыш, суда утырса да, бар үләннән элек корый.
- Камыш судан туймас.
- Камышны үз күлеңнән ал.
- Камышы күренсә, чишмәсе табылыр.
- Корыган камыш еpактан тавыш бирер.
- Куянны камыш үтерә, ирне намус үтерә.

**КӘБЕСТӘ**

▪ Кәбестә аркасында суган да су эчә.

**КЕРӘН**

▪ Керән тормадан татлы булмас.

**КИНДЕР**

▪ Киендерсәң, киндер таягы да кияү була.
▪ Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең.
▪ Киндердән киндер дә була, киндераш та була.
▪ Киндердән сүс чыгар, сүс чыкмаса, чүбек чыгар.
▪ Киндерне суккан вакытта кытыршы калдырсаң, киявең шадра булыр.

**КИШЕР**

▪ Кишер – эчеңә килешер.

**КОЛМАК**

▪ Җәй көне томан күп булса колмак үсәр, томан булмаса – үсмәс.
▪ Мартның әүвәлге якшәмбесендә җылы булса – ашлык уңар, кар яуса – чикләвек, колмак уңар.

**КӨНБАГЫШ**

▪ Бер уч көнбагыш ашасаң, ике уч кабыгы чыгар.
▪ Игезәк чикләвек яки көнбагышның бер төшен кешегә бирергә, берсен үзең ашарга кирәк. Икесен дә үзең ашасаң, игез бала табасың.

**КУБА ТАЛ, КОБА ТАЛ**

▪ Куба тал шарт сынар, сары тал йөгенеп калыр.

**КУЗГАЛАК**

▪ Кузгалак күп булса, кыш салкын була.
▪ Кузгалак көпшәсе юан булса, киндер бик уңар.

**КУРА**

▪ Җил исми(чә), кура селкенми.

**КУРА ҖИЛӘГЕ**

▪ Вакыты үткәч, кура җиләге җыярга барма.
▪ Кура җиләге кураның башыннан өлгерсә – ашлык яхшы булыр, төптән өлгерсә – начар булыр.
▪ Кура җиләге эре булса, киләсе елга ашлык башаклы булыр.

▪ Кура җиләгенең элек өлгергәне эре булса, ашлыкның иртә чәчкәне уңар.

**КЫЛГАН**

▪ Кылган башы юкка кымшанмый.

**КЫНА**

▪ Кына ташка бетәр.

**КЫРЛЫК**

▪ Чүпле орлык чәчкәннең кырын кырлык басар.

**КЫРМАВЫК**

▪ Кырмавык үзенә тигән һәркемгә ябыша.

**КЫЧЫТКАН**

▪ Кычыткан сабагында мәк үсмәс.
▪ Алда – гөл, артта – кычыткан.

**КЫЯР**

▪ Декабрьнең егерме бишендә, егерме алтысында, егерме җидесендә тамчы булса, кыяр, тары булмас, карабодайга килешер.
▪ Май алтысында булса чык – ул ел кыярга тук.
▪ Март берендә аязлык – җәй көн кыярга туклык.

**МӘК**

▪ Мәк ашаган тиз йоклар.
▪ Мәкнең бер сабагы – дару, бер сабагы – агу.

**МӘТРҮШКӘ**

▪ Сары мәтрүшкә алтмыш төрле авырудан, көрән мәтрүшкә җитмеш төрле авырудан дәва.

**МИЛӘШ**

▪ Җәй көне миләш уңса – арыш яхшы булыр, шомырт уңса – начар булыр.
▪ Миләш дигән җимеш авыздан – су, күздән яшь китерер.
▪ Миләш диеп капкан идем, балан булып чыкты бу.
▪ Миләш күп булган елны чир күп була.
▪ Миләш уңган елны арышны күп чәчәргә кирәк. Уңыш күп булачак.
▪ Миләштән бәлеш салмыйлар.

- Сиртмәгә миләш агачын ишле төптән алсаң, бала ишле була.

**НАРАТ**

- Нарат – башыннан, имән төбеннән корый.
- Нарат төз карап үсәр, иянке иялеп үсәр.

**НОГЫТ**

- Ногыт борчагы биек булса, киндер бик уңар, сабан ашлыгы да уңар.

**ӨРЕК**

- Өлгергән өрек сабагында тормый.

**ӨЯНКЕ**

- Нарат төз карап үсәр, өянке өяләп үсәр.

**ПАҢГЫ**

- Паңгы булдыңмы – кер кызауга.

**ПӘҖЕ / ПӘҖИ**

- Пәҗи килегә кермичә, мае чыкмас.

**РОЗА, ГӨЛЧӘЧӘК**

- Роза чәнечкесез булмый.

**САРАНА**

- Сарана төбендә суган ятыр.

**САРЫМСАК**

- Сарымсак хаҗга барып кайтса да татлыланмас.

**САРЫ ЧӘЧӘК**

- Сары чәчәкне өзәргә ярамый – җил чыга.

**СӘРБИ**

- Сәрбидәге кузаклар шартлый башлау белән арыш урырга ярый.

**СОЛЫ**

- Беренче гыйнварда җылы булса – арыш уңар, җил булса – тары уңар, томан булса – солы уңар.
- Озынборыннар яздан ук югары болгансалар, солы бик уңар.
- Солы чәчеп бодай көтмиләр.
- Солыны кибәктән аера алмау.

- Солысыз ат йөрми.
- Чикләвек агачында бөре күп булса, солы уңар.

**СУГАН**

- Сарана төбендә суган ятыар.
- Суган кабыгы калын булса, кыш салкын була.
- Суган кабыгы сигез кат.
- Суган сирәк булса, башы олы булыр.
- Суган тураганда күзеңә ачысы кермәсә, көндәшкә чыдыйсың, имеш.
- Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы булыр, әгәр суганның кабыгы күп кат булса, кыш салкын булыр.
- Суганның татлысы юк.
- Суфый суган сөймәс, күрсә – кабыгын да куймас.

**СЫРЛАН**

- Сырланның үзен өзсәң дә тамыры кала.

**ТАЛ**

- Куба тал шарт сынар, сары тал йөгенеп калыр.
- Сыгылмалы тал сынмый.
- Тал дым ярата, усак ком ярата.
- Талны чыбык чагында бөгәләр.

**ТАРЫ**

- Арыш уңса ун булып, тары уңар мең булып.
- Барыс елны барын чәч, һич булмаса, тары чәч.
- Барыс елны бары чыгар, бары чыкмаса, тары чыгар.
- Бер тарыдан ботка булмый.
- Тары колактан беленер.
- Ташлык җиргә тары чәч.
- Торна кар барында килсә, тары, борчак уңар.
- Тургайдан курыксаң, тары икмә.
- Үрдәкләр түбән очса, тары уңар.
- Чәчелгән тарыны чүпләү читен.

**ТИГӘНӘК**

- Гөлдән – тигәнәк, тигәнәктән гөл чыкмас.
- Тигәнәк әрекмәннән ерак китми.
- Тигәнәк булып аякка кадалганчы, гөл булып якага кадал.
- Тигәнәк чәчеп бодай ура алмассың.

### ТИРӘК

- Кирәк тирәкне ега.
- Корыган тирәк су янында да яшәмәс.
- Тирәк төптән егылыр.

### ТОРМА

- Ачы торманың сирәге яхшы.
- Берәүгә торма кирәк, берәүгә хөрмә кирәк.
- Сирәк торма төпле була.
- Тоз сипсәң, торма да төче була.

### ТУБЫЛГЫ

- Тубылгы агач зур булмас, тубылгыдан өй булмас.

### ТУЗ

- Туздырма тузны – колагың чукракланыр.
- Туздырма тузны, кыздырма кузны.

### УМЫРЗАЯ

- Умырзаяның гомере бер көн.

### УСАК

- Усак агачында алма үсми.
- Чатлы-ботлы карама булыр, шарт-шорт янган усак булыр.

### УТ ЧӘЧӘГЕ

- Ут чәчәген өйгә кертсәң, янгын була.

### ҮЛӘН

- Апрель сулы булса, май үләнле булыр.
- Кыш көне кырдагы үлән кайсы якка таба бөгелсә, җәй көне ашлык шул якка таба бөгелер.
- Олы юлга үлән үсми.
- Питрауга чаклы үләннең шифасы чәчәктә, Питраудан соң – тамырда.
- Үлән башыннан корыр.
- Үләнле җирне урт алмас.

### ЧӘЧӘК

- Чәчәкләр хуш ис бөркесә, эссе булыр.

**ЧИКЛӘВЕК**

- Декабрьнең егерме бишендә көндез кар яуса, чикләвек яхшы булыр.
- Мартның әүвәлге шимбәсендә кар яуса чикләвек һәм карабодай уңар.
- Чикләвек агачы эчтән чери.

**ЧИЯ**

- Өч көн үтте – чия чәчәге шиңде.
- Чия яфраклары коелмый торып, күпме кар яуса да барыбер эреп бетә.

**ЧӨГЕНДЕР**

- Җимеш юк җирдә чөгендерне дә әфлисун диләр.

**ЧЫРШЫ**

- Чыршы күркәләре башында булса – ашлыкны иртә чәч, әгәр дә төбендә булса – соң чәч.

**ШАЙТАН ТАЯГЫ**

- Шайтан таягына кырау тими.
- Шайтан таягы чүплек башында.

**ШАЛКАН**

- Аңа бит алма – шалкан, ком – талкан.
- Бодай чәчсәң – башагын җый, шалкан чәчсәң – тамырын җый.
- Мич башында шалкан пешми.
- Сентябрь унбишендә каз очса кышларга, шалкан кис базга ташларга.
- Шалканны ефәккә төргәннән бәясе артмас.

**ШОМЫРТ**

- Шомырт уңган елны ачлык булыр, алма уңган елгы туклык булыр.
- Шомырт уңган елны иген уңмый, чикләвек уңган елны иген дә уңа.
- Шомырт чәчәк аткач, кызлар җилкенә, балан чәчәк аткач, балык сикерә.
- Шомыртка көя төшмәсә, сабан ашлыгы начар була.

**ЭРГӘЗЕМБАЙ**

- Эргәзембай – яз күрке.

### ЭТ ЭЧӘГЕ

- Эт эчәгенең очы-башы булмас.

### ЮКӘ

- Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.
- Юкә өзсәң, каеш түләрсең.
- Юкә чәчәге коела башласа, арыш чәчәргә вакыт.
- Юкә чөй тумран яра.
- Юкәне майлау белән каеш булмас.
- Юкәнең агачы юкә түгел, кабыгы юкә.
- Юкәнең чәчәге – бал, кабыгы – юкә, череге – дару, агачы – сөян.

### ЯШЕЛЧӘ

- Март башы көн кояшлы булса, яшелчә уңа.